ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектларын саклап калу, файдалану, популярлаштыру һәм дәүләт саклавы чаралары турында

«Хөкүмәт сәгате» кысаларында Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты рәисе И.Н. Гущинның Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектларын саклап калу, файдалану, популярлаштыру һәм дәүләт саклавы чаралары турындагы мәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты рәисе И.Н. Гущинның мәгълүматын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектларын саклап калуда, торгызуда һәм популярлаштыруда комплекслы алымны тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының һәм Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарының ведомствоара хезмәттәшлеген камилләштерү эшен дәвам итүне тәкъдим итәргә.

3. Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитетына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

3.1. Региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектларының, җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларының, ачыкланган мәдәни мирас объектларының торышына, аларны тотуга, саклап калуга, алардан файдалануга, аларны популярлаштыруга һәм дәүләт саклавына региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруны дәвам итәргә.

3.2. Тарихи һәм мәдәни кыйммәткә ия объектларны ачыклау һәм дәүләт саклавына куую эшен дәвам итәргә.

3.3. Татарстан Республикасы муниципаль районнарына һәм шәһәр округларына мәдәни мирас объектларын саклап калу һәм популярлаштыру мәсьәләләрен хәл итүдә ярдәм күрсәтергә, методик яктан тәэмин итәргә.

3.4. Территорияләрендә тарихи җирлекләр урнашкан Татарстан Республикасындагы җирле үзидарә органнары белән бергә Татарстан Республикасында тарихи җирлекләрнең тотрыклы үсешен тәэмин итү эшен дәвам итәргә.

3.5. Мәдәни мирас объектларын саклап калу буенча аерым төр эшләрне башкаруга ихтыярый ярдәм итүчеләрне (волонтерларны) җәлеп итү эшен дәвам итәргә.

4. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитетына Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектларын саклап калу, файдалану, популярлаштыру һәм дәүләт саклавы өлкәсендәге законнарны гамәлгә ашыруны тикшереп тору эшен дәвам итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2024 елның 6 июне
№ 2531-VI ДС